**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Чистай районының Байтирәк авылы территориясендә терлекләр котыру авырулы булганга, аның иминлексезлеге сәбәпле кертелгән карантинны бетерү турында**

Терлекләрнең котыру белән чирләвенең соңгы очрагыннан соң ике ай узуы, эпизоотиягә каршы һәм профилактик чаралар уздырылу белән бәйле рәвештә, «Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-I номерлы Россия Федерациясе Законының $3^1$ статьясы нигезендә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Чистай районының Байтирәк авылы территориясендә терлекләр котыру авырулы булганга, аның иминлексезлеге сәбәпле кертелгән карантинны бетерергә.

2. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Чистай районының Байтирәк авылы территориясендә терлекләр котыру авырулы булганга, аның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертү турында» 2020 елның 16 гыйнварындагы ПУ-12 номерлы Указы үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2020 ел, 24 март
№ ПУ-190